■ Иманга юл

# ШИРЕКНЕҢ КУРКЫНЫЧЛЫГЫ

Нинди гөнаһны Аллаһ тәгалә тәүбәсез кичерми? Нинди гөнаһ сәбәпле аны кылучы өчен җәннәт хәрамга әйләнә? Нинди гөнаһ сәбәпле аны кылучы мәңгегә Тәмугка эләгә? Нинди гөнаһ бөтен яхшы гамәлләрне юкка чыгара? Нинди гөнаһ Галәмнәр Раббысы - Аллаһны хурлау булып тора?

Бу - Аллаһ тәгаләне мәхлукларга тиңләү, Аңа тиңдәшлек (ширек) китерү, гыйбадәтне Аннан башкага багышлау. Бу - бүгенге көндә күп мөселманнар эшли торган гөнаһ. Ширек - иң зур гөнаһ.

Чынлыкта, ширек - иң зур золым-гаделсезлек, наданлыкның ахыргы чиге, һәм шуңа күрә барлык рәсүл һәм пәйгамбәрләр дәгъвәтләрен (дингә өндәүләрен) хак тәүхид - берилаһелеккә чакырудан.

Ә хак тәүхид - ул ширекнең капма-каршысы. Пәйгамбәрләр ширекне инкарь иткән кебек, бернәрсәне дә инкарь итмәгәннәр, Коръәндә һәм Мөхәммәд салләллаһу аләйһи үә сәлләм хәдисләрендә булган иң зур кисәтүләр - ул ширек кылучыларга карата булган кисәтүләр.

Аллаһ тәгалә Үзенең Китабы - Коръәндә әйтә: **“Чынлыкта, Аллаһ Үзенә тиндәш тотуны ярлыкамый, әмма аннан башка (яки аннан кече) гөнаһларны теләгәненә ярлыклар. Аллаһыга тиңдәш тотучы олы адашу белән адашкандыр!”**. “ән-Ниса” сүрәсе, 48 аять.

Шулай ук: **“Хакыйкатьтә, кем Аллаһыга карата ширек кылса, аны Аллаһ җәннәттән мәхрүм итә, һәм аның сыенып урыны - Ут! Һәм залимнәргә ярдәм итүчеләр юктыр!”**. “әл-Маидә” сүрәсе, 5:72.

Аллаһ Тәгалә иң яхшы кешеләр - пәйгамбәрләр турында нәрсә әйтә: “Әгәр дә Аңа карата ширек кылсалар, аларның кылган гамәлләре юкка чыгар иде!”. “Әл-Әнгам” сүрәсе, 6:88.

Аллаһ Тәгалә Үзенең иң яхшы рәсүле - Мөхәммәдкә (салләллаһу аләйһи үә сәлләм) нәрсә әйтә: **“Сиңа һәм синнән элек булганнарга вәхи ителде: Әгәр син Аллаһыга тиңдәш тотсаң (ширек кылсаң), синең эшләрең һичшиксез юкка чыгар, һәм син, әлбәттә, зарар күрүчеләрдән булырсың”. Аллаһка гына гыйбадәт кыл һәм шөкер итүчеләрдән бул”.** “Әз-Зүмәр” сүрәсе, 39:65-66.

Аллаһының Илчесе (Аллаһның аңа сәләм һәм салаватлары булсын) безне ширектән кисәткән. Габдуллаһ ибне Мәсгуд (Аллаһ аңардан разый булсын) әйткән: **“(Бервакыт) Аллаһының Илчесе (салләллаһу аләйһи үә сәлләм) әйтте: “Аллаһ белән бергә башкага гыйбадәт кылып үлүче Утка керәчәк”, һәм мин әйттем: “Аллаһтан башка беркемгә дә гыйбадәт кылмыйча үлүче Җәнәткә керәчәк”** Бохари, 1238.

Җәбир ибне Габдуллаһ (Аллаһ аңардан разый булсын) сөйләвенчә, Мөхәммәд салләллаһу аләйһи үә сәлләм әйткән: **“Кем Аллаһыга тиңдәшләр китермичә үлә икән, шул җәннәткә, ә кем Аңа тиңдәшләр тотып, ширек катып үлә икән, шул Утка керәчәк”**. Мөслим, 93.

Мүгаз ибне Җәбәл (Аллаһ аңардан разый булсын) сөйләгән: **“Бервакыт мин ишәктә, Пәйгамбәр (салләллаһу галәйһи үә сәлләм) артында барганда, ул әйтте: “Йә Мүгаз! Беләсеңме син Аллаһының колларына, ә колларның Аллаһка нинди хакы бар?” Мин: “Аллаһ һәм Аның Илчесе әйбәтрәк белүчедер, - дип әйттем”. Ул әйтте: “Чынлыкта, Аллаһның колларына карата булган хакы - аларның Аддаһка гына гыйбадәт кылулары һәм Аңа бернинди тиңдәшлек (ширек) китермәүләрендә, ә колларның Аллаһ Тәгаләгә карата булган хаклары - Аллаһының Аңа бернәрсәне дә тиңдәш итмәүчеләрне газапламавында”.** Мөслим, 30.

Әбү Зәрр (Аллаһ аңардан разый булсын) сөйләгән: **“Пәйгамбәр (салләллаһу галәйһи үә сәлләм) әйтте: “Минем яныма Җәбраил килде һәм мине яхшы хәбәр белән шатландырды: “Минем өммәтемнән булучы үлсә, һәм ул Аллаһка бернәрсәне дә ширек китермәгән булса, ул Җәннәткә керәчәк”. Сәхаби сорады: “Ул зиначы һәм урлашкан булса дамы?” Пәйгамбәр (салләллаһу галәйһи үә сәлләм) әйтте: “Ул зиначы һәм урлашкан булса да”**. Бохари, 3222; Мөслим, 94.

Сәгыйть ибн әл-Мүсәййиб этисеннән хәбәр иткән: **“Әбү Талиб үлеп ятканда, аның янына Аллаһының Илчесе (салләллаһу галәйһи үә сәлләм) килә. Бу вакытта Әбү Талиб янында әбү Җәһел һәм бин әбү Үмәййә ибнел-Мугыйра булалар. Аллаһының Илчесе (салләллаһу галәйһи үә сәлләм) әйтә: “Ий, абый! “Лә иләһә иләллаһ”** - дип әйт, бу кәлимә аркылы мин синең өчен Аллаһ каршында шәһадәт итәрмен”. Әбү Җәһел һәм Габдуллаһ бин әбү Үмәййә: Йә, әбү Талиб, Габдел-Мотталиб диненнән баш тартасыңмы?” - дип әйтәләр. Әбу Талиб әйтә: **“Мин, Габдел-Мотталиб динендә калам”, һәм “Лә иләһә илләллаһ” - дип әйтүдән баш тарта. Аллаһының Илчесе (салләллаһу галәйһи үә сәлләм) әйтә: “Аллаһ белән ант итәм, мин һичшиксез синең өчен гафу итүне сорармын”**. Шуннан Аллаһ Тәгалә әлеге аятьләрне индерә:

Ногмани тәфсиреннән:

**“Пәйгамбәргә вә мөэминнәргә, мөшрикләр, кәферләр вә динсезлекләргә Аллаһудан гафу сорап дога кылмак һич дөрес түгел, гәрчә алар ата-аналары вә башка кардәшләре булсалар да, аларның җәһәннәмгә керәчәкләре белән хәбәр бирелгәннән соң.** “(Тәүбә сүрәсе, 113 аять)” (Мөслим).

## Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Зөлхизә-Мөхәррәм 2012 миләди йыл**
**1433 һижри йыл.**

| Зөлхизә Мөхәррәм | Аҙна көндәре | Ноябрь, Декабрь | Иртәнге намаҙ | Ҡояш сыға | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Кесе йома | 15 | 8.19 | 9.49 | 14.30 | 16.41 | 18.11 | 19.41 |
| 2 | Йома | 16 | 8.21 | 9.51 | 14.30 | 19.39 | 18.09 | 19.39 |
| 3 | Шәмбе | 17 | 8.23 | 9.53 | 14.30 | 19.38 | 18.08 | 19.38 |
| 4 | Йәкшәмбе | 18 | 8.25 | 9.55 | 14.30 | 16.36 | 18.06 | 19.36 |
| 5 | Дүшәмбе | 19 | 8.27 | 9.57 | 14.30 | 16.35 | 18.05 | 19.35 |
| 6 | Шишәмбе | 20 | 8.29 | 9.59 | 14.30 | 16.33 | 18.03 | 19.33 |
| 7 | Шаршамбы | 21 | 8.31 | 10.01 | 14.30 | 16.32 | 18.02 | 19.32 |
| 8 | Кесе йома | 22 | 8.33 | 10.03 | 14.30 | 16.31 | 18.01 | 19.31 |
| 9 | Йома | 23 | 8.35 | 10.05 | 14.30 | 16.30 | 18.00 | 19.30 |
| 10 | Шәмбе | 24 | 8.36 | 10.06 | 14.30 | 16.28 | 17.58 | 19.28 |
| 11 | Йәкшәмбе | 25 | 8.38 | 10.08 | 14.30 | 16.27 | 17.57 | 19.27 |
| 12 | Дүшәмбе | 26 | 8.40 | 10.10 | 14.30 | 16.26 | 17.56 | 19.26 |
| 13 | Шишәмбе | 27 | 8.42 | 10.12 | 14.30 | 16.25 | 17.55 | 19.25 |
| 14 | Шаршамбы | 28 | 8.43 | 10.13 | 14.30 | 16.24 | 17.54 | 19.24 |
| 15 | Кесе йома | 29 | 8.45 | 10.15 | 14.30 | 16.23 | 17.53 | 19.23 |
| 16 | Йома | 30 | 8.47 | 10.17 | 14.30 | 16.22 | 17.52 | 19.22 |
| 17 | Шәмбе | 1 | 8.48 | 10.18 | 14.30 | 16.21 | 17.51 | 19.21 |
| 18 | Йәкшәмбе | 2 | 8.50 | 10.20 | 14.30 | 16.21 | 17.51 | 19.21 |
| 19 | Дүшәмбе | 3 | 8.51 | 10.21 | 14.30 | 16.20 | 17.50 | 19.20 |
| 20 | Шишәмбе | 4 | 8.53 | 10.23 | 14.30 | 16.19 | 17.49 | 19.19 |
| 21 | Шаршамбы | 5 | 8.54 | 10.24 | 14.30 | 16.19 | 17.49 | 19.19 |
| 22 | Кесе йома | 6 | 8.56 | 10.26 | 14.30 | 16.18 | 17.48 | 19.18 |
| 23 | Йома | 7 | 8.57 | 10.27 | 14.30 | 16.18 | 17.48 | 19.18 |
| 24 | Шәмбе | 8 | 8.58 | 10.28 | 14.30 | 16.17 | 17.47 | 19.17 |
| 25 | Йәкшәмбе | 9 | 8.59 | 10.29 | 14.30 | 16.17 | 17.47 | 19.17 |
| 26 | Дүшәмбе | 10 | 9.01 | 10.31 | 14.30 | 16.17 | 17.47 | 19.17 |
| 27 | Шишәмбе | 11 | 9.02 | 10.32 | 14.30 | 16.16 | 17.46 | 19.16 |
| 28 | Шаршамбы | 12 | 9.03 | 10.33 | 14.30 | 16.16 | 17.46 | 19.16 |
| 29 | Кесе йома | 13 | 9.04 | 10.34 | 14.30 | 16.16 | 17.46 | 19.16 |
| 1 | Йома | 14 | 9.05 | 10.35 | 14.30 | 16.16 | 17.46 | 19.16 |
| 2 | Шәмбе | 15 | 9.06 | 10.36 | 14.30 | 16.16 | 17.46 | 19.16 |

■ Кыйсса

# Яхшы сүз - җан азыгы

Беркөн Солтан Мәхмүд Газнәви юлда барганда күрде: бер карт бакча ясый, җимеш агачлары утырта.

Солтан сорады:

- Әй карт! Бу бакчаны кем өчен утыртасың?

Карт:

- И падишаһ! Башкалар үстерде - без җимеш ашадык, инде мин үстерәм - башкалар ашасын, - диде.

Бу сүз солтанга ошады:

- Дөньядагы күп эшләр шуның кебек бер-берсенә бәйләнешле, мәгънәле сүз әйттең, - дип, картка мең алтын бирде.

Солтан китеп барганда, карт әйтте:

- И әфәндем! Башкалар бакча үстерәләр, берничә елдан соң гына җимешләрен татыйлар, ә мин утырткан көнне үк татый башладым, гаҗәп түгелмени? - диде. Бу сүз дә солтанның күңеленә хуш килде, яңадан мең алтын динар бирде. Артыннан карт тагын кычкырды:

- И мәхдүм! Башкалар бакчаның җимешен елга бер тапкыр җыялар, ә мин бер көндә ике тапкыр җыйдым, гаҗәп түгелме? - диде. Солтанга тагын хуш килде, тагын мең динар бирде.

Солтан китеп барганда, тагын берәр сүз әйтү өчен карт яңадан аваз бирде.

Вәзир әйтте:

- И солтаным! Тизрәк китик, югыйсә бу зирәк карт сүз белән бөтен байлыгыбызны алыр, - диде.

# Юмарт карт һәм игътибарсыз падишаһ

Беркөн Мәхмүд Насретдин Газнәви ауга чыкты. Иярченнәреннән һәм хезмәтчеләреннән аерылып киткән иде. Ачлык һәм сусызлык үзәгенә үтте. Шул вакытта күрде: бер карт җилкәсенә алма күтәреп килә.

Солтан әйтте:

- Әй карт! Нәрсәң бар?

Карт:

- Бераз сулы, татлы алмам бар, падишаһка илтәм, - диде. - Ул, бәлки, минем хакымда бер яхшылык итәр, балаларым күп, - диде.

Солтан әйтте:

- Миңа бераз бирмәссеңме, кулыңнан килерме?

Карт:

- Булыр, - диде. Кәрзиннең авызын ачты, алдына куйды: - Никадәр теләсәң, ал! - диде.

Солтан бераз алма алып, куенына салды, ашый-ашый китте. Гаскәренә җитеште. Әйтте:

- Шундый-шундый рәвешле карт килсә, юл бирегез, - диде. Алмасы бераз калган икән, вәзирләре Хуҗа Хәсәнгә һәм Аязга бирде.

Бераз вакыттан соң карт килде. Юл бирделәр. Керде, алманы тәхет алдына, солтан каршысына куйды. Дога кылды. Кире чигенеп, бер почмакка барып утырды.

Казага каршы, берничә җинаятьчене китерделәр. Хәлләрен сорап тормастан, карт алар янына утырган иде. Солтан ул җинаятьчеләрнең хәлен белгәч, аларны зинданга җибәртте. Сакчылар ялгышлык белән картны да шулар арасында зинданга салдылар. Бакчачы карт солтанның хәтереннән чыккан иде.

Бу хәлләрдән соң бер ел үтте. Беркөн солтан начар төш күрде. Иртән төрмәләгеләрне чакыртты, һәрберсенең хәлен сорашты, азат итеп, кием бирәчәгенә кием бирде, үтереләчәген үтертте. Чират картка җитте. Солтан:

- Син бу картаймыш көнендә нинди гөнаһ кылдың? - диде.

Карт:

- Һич гөнаһым булмады, булса шул булгандыр: берәр нәрсә өмет итеп, сиңа алма алып килгән идем, бер ел инде зинданда рәнҗеш чиктем, - диде.

Солтан моны ишетеп, күңеле бозылды, үкенде. Карттан гафу үтенде, аны хәзинәсенә кертте:

- Ни теләсәң - шуны ал! - диде.

Карт хәзинәгә керде. Бер китап, бер балта һәм бер алтын динар алды. Хәзинәче бу хәлне күреп бик гаҗәпләнде. Бу хакта солтанга килеп әйтте. Солтан картны чакыртып сорады:

- Шулкадәр нигъмәттән ни өчен зуррак нәрсә алмадың? - диде.

Карт:

- Солтанның яше озын булсын, мин зәгыйфь кеше, балта тота алмыйм, бу алтын белән балтаны бер кешегә бирәм, алмагачларны кистерәм, шулар аркасында тагын газапка дучар булмыйм. Ә китапны исә шуның өчен алдым: бер яшь улым бар, аны мәктәпкә бирәм, минем кебек бакчачы итмим, алмагач үстертмим, - диде.

Солтан таң калды, игътибарсызлыгына үкенде. Аннан соң картка биш мең динар бирергә боерды.

■ Фикер

# АК ТӨС ТУРЫНДА

**Исламия ЛАТЫПОВА**
***Казан шәһәре***

Кыйгы районы Арслан авылында 1950-60 елларда бердән-бер намаз укучы Ак әби бар иде. Ул минем классташым Вәрис Низаметдиновның - дәү әнисе. Аның исемен бер кем дә хәтерләми, бары тик шул кушамат белән аңа дәшәләр иде.

Ул урамга чыкканда сумкасына ак яулыгын, күлмәген, намазлыгын салып йөртә, ә инде өйлә, икенде вакытлары җитсә (намаз вакытын кояшка карап билгели), урамдагы теләсә кайсы йортка кереп, намазлыгын җәеп, сумкасындагы яулыгын ябынып, күлмәген киеп, намаз укып, догалар кылып, изге теләкләр теләп, юлын дәвам итә иде.

Җәй көннәрендә репрессиягә дусар ителгән бабайларның хатыннары - ак яулык, ак ефәк шәлләр ябынган, каелган читекләр, бала итәк күлмәкләр кигән абыстайлар - Томскидан, Омскидан, Иркутск өлкәләреннән кайтып, безгә үрнәк күрсәтә иделәр. Аларның җитәкчесе Өмкамал Уелданова әби булды. Алар йорттанйортка кереп, дога кылып, Ислам динен таратып, дәгъват кылучылар булдылар. Бер вакытта да ачы тормышка, тискәре йогынтыларга исләре дә китмичә, туып үскән җиренә, иленә, ирләренә тугры калдылар.

Мөхәммәд(с.г.с.) өч төсне сөннәт дип билгели: ак, яшел, кара, ләкин ак төс яхшырак, диелә. Бала тугач та ак биләүгә биләнә, гаилә корганда ирләр дә, хатыннар да - ак күлмәктә, соңгы туенда кәфене дә ак төстә була. Гомумән, кара төс ирләр өчен генә хас, диеп исәпләнә. Шәкертләребезнең чит илләрдә укып, алардан алып кайткан горефләре безнең халык өчен хас түгел. Идел буенда яшәүче мөселман хатын-кызлары баштан аякка кадәр кара төсне кимәгән. “Ак әби”, “Ак бабай”, “Ак алъяпкыч”, “Аксакал” дигән төшенчәләр гомер буе булган. Алар әдәбияттә, телдә сакланып калган. Шуңа күрә ак төс - пак төс, саф төс, тормышта да иң алгы рәттә торучы төс булган. Һәр хажи дә хаж, гомрә кылганда ат төстән ихрам кия.